**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЗУР КУККУЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2023 ел, 14 август № 105

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Зур Куккуз авыл җирлеге Советы карар кылды:

1.Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1)физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр закон буенча да, васыять буенча да варислары булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алу хокукына ия булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның барсы да мирас алудан баш тартса һәм аларның берсе дә башка кеше файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2)салым түләүче физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3)салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән өч еллык срокның тәмамлануы;

4)бетерелгән җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы.

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне җирлек башлыгана йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Зур Куккуз авыл җирлеге Советы рәисе –**
**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Зур Куккуз авыл җирлеге Башлыгы Низамова Р.Ф.**